| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11.04.2022 Баулы шәһәре № 58

Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү, төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү һәм тәртип саклау турында»гы 2017 елның 25 октябрендәге 60 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Конституция судының 2021 елның 19 апрелендәге 14-П номерлы «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» Федераль законның 209 статьясындагы 2 пунктының, 10 статьясындагы 7 өлешенең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча» карары, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 45.1 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктының 2, 16 статьясындагы 1 өлешенең 25 пунктының һәм 2 пунктының егерме икенче абзацы нигезендә, гражданнар Г.С. Дадашов, И.Н. Касыймов һәм башкалар шикаятьләренә бәйле рәвештә, Баулы шәһәр Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү, төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү һәм тәртип саклау турында»гы 2017 елның 25 октябрендәге 60 номерлы карарына (2020 елның 29 маендагы 131 номерлы, 2021 елның 18 февралендәге 23 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. пунктының 26 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«калдыкларны урнаштыру - калдыкларны саклау һәм күмү; калдыкларны саклау - бу утильләштерү, зарарсызландыру, күмү максатларында, унбер айдан артык вакыт эчендә махсуслаштырылган объектларда калдыклар җыю»;

4 нче бүлекнең 4.1. пунктындагы в) пунктчасын төшереп калдырырга;

4 нче бүлекнең 4.1 пунктындагы г) пунктчасын төшереп калдырырга;

4 бүлекнең 4.8 пунктындагы г) пунктчасында «йорт биләмәләре чикләрендә яшел үсентеләрне тәртиптә тотарга, куакларны һәм агачларны санитар кисеп алырга» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 бүлекнең 4.8. пунктындагы д) пунктчасын төшереп калдырырга;

4 бүлекнең 4.8 пунктындагы з) пунктчасын төшереп калдырырга;

5 нче бүлекнең 5.5 пунктындагы н) пунктчасын төшереп калдырырга;

10 нчы бүлекнең 10.1 пунктындагы 35-41 абзацларын төшереп калдырырга;

10 нчы бүлекнең 10.1. пунктындагы 25 абзацында «терлекчелек продуктларын» сүзләрен «терлекчелек продукциясен» сүзләренә алмаштырырга.

Баулы шәһәре Мэры вазифаларын
башкаручы, шәһәр Советы Рәисе
вазифаларын башкаручы –
Баулы шәһәре Мэры урынбасары,
шәһәр Советы Рәисе урынбасары К.Ф. Корбанов